КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2023 ел, 5 октябрь

г.Казань

№ 1235

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын уздыру турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын уздыру турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 август, 642 нче; 2021 ел, 16 апрель, 254 нче; 2021 ел, 13 август, 717 нче; 2022 ел, 26 июль, 719 нчы; 2023 ел, 20 апрель, 508 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Ел инженеры» республика конкурсы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Ел инженеры» республика конкурсын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составында:

Юрий Михайлович Казаковның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Тимур Лазович Алибаевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы

Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 22 апрель, 325 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 5 октябрь, 1235 нче
карары редакциясендә)

# «Ел инженеры» республика конкурсы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмәдә «Ел инженеры» республика конкурсын (алга таба – конкурс) уздыру максаты һәм тәртибе билгеләнә.

1.2. Конкурс түбәндәге максатларда уздырыла:

конкрет проектны гамәлгә ашыруда югары дәрәҗәдә компетентлык күрсәткән һәм мөстәкыйль рәвештә яки коллектив составында нәтиҗәләргә ирешкән инженер һөнәрләре вәкилләрен ачыклау һәм бүләкләү;

инженер хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм хезмәтләренең җәлеп итүчәнлеген арттыру;

Татарстан Республикасында инженер һөнәрләренең нәтиҗәле кадрлар потенциалын булдыру;

Татарстан Республикасының иң яхшы инженерлары казанышларын пропагандалау;

яшьләр мохитендә инженерлык хезмәте белән кызыксынуны арттыру;

Татарстан Республикасының иң яхшы инженерлары буенча мәгълүмат банкын булдыру.

1.3. Конкурс үткән календарь елга инженерлык эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча уздырыла.

1.4. Конкурс Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге коммерция яисә коммерциягә карамаган оешмаларда яки югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларында (алга таба шул ук эзлеклелектә – предприятие, югары белем бирү оешмасы) эшләүче, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары яисә югары белем бирү оешмаларында белем алучылар арасында уздырыла.

1.5. Конкурс өч категориядә уздырыла: «Булачак инженерлар», «Яшьлек, уңыш, перспектива», «Тәҗрибә, казанышлар, компетентлык».

«Булачак инженерлар» категориясендә югары белем бирүнең мәгариф программалары – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча югары белем бирү оешмаларында белем алучылар катнашырга хокуклы.

«Яшьлек, уңыш, перспектива» категориясендә 35 яшькә (35 яшьне кертеп) кадәрге вазыйфаи бурычлары инженерлык эшчәнлеге белән бәйле югары белемле предприятиеләр хезмәткәрләре йә инженерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче югары белем бирү оешмалары хезмәткәрләре, аспирантлары катнашырга хокуклы.

«Тәҗрибә, казанышлар, компетентлык» категориясендә 35 яшьтән олырак вазыйфаи бурычлары инженерлык эшчәнлеге белән бәйле югары белемле предприятиеләр хезмәткәрләре яисә инженер эшчәнлеге белән шөгыльләнүче югары белем бирү оешмалары хезмәткәрләре катнашырга хокуклы.

1.6. Конкурс һәр өч категориянең түбәндәге 12 номинациясе буенча уздырыла:

машина төзелеше (автомобиль төзелеше, суднолар төзелеше, станоклар төзелеше һ.б.);

авиация сәнәгате;

приборлар төзү, шул исәптән оптик электрон һәм медицина приборлары төзү;

радиоэлектроника, элемтә, фотоника, телекоммуникацияләр;

газ сәнәгате;

нефть сәнәгате;

химия, нефть химиясе, биотехнологияләр;

энергетика

җиңел, агач эшкәртү, целлюлоза-кәгазь сәнәгате;

төзелеш, төзелеш материаллары җитештерү;

транспорт, юл хуҗалыгы;

авыл хуҗалыгы, азык-төлек, эшкәртү сәнәгате.

1.7. Конкурста җиңүчеләр киләсе өч конкурста катнаша алмыйлар.

## II. Конкурсны оештыручылар

2.1. Конкурс, республика башкарма хакимият органнарын, башка оешмаларны һәм эксперт берләшмәләрен җәлеп итеп, Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) ярдәмендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) тарафыннан уздырыла.

2.2. Конкурсны әзерләү һәм уздыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештыру комитеты төзелә.

2.3. Оештыру комитеты:

конкурсны әзерләү һәм уздыру белән оператив җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

конкурста катнашучыларның казанышларын бәяләү өчен конкурс комиссиясе составын раслый;

конкурс уздыру срокларын, аңа документлар бирү тәртибен билгели;

конкурсның оештыру мәсьәләләрен хәл итә;

әлеге Нигезләмәгә таянып башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.4. Конкурс башлану, конкурска документлар тапшыру сроклары һәм урыны турында мәгълүмат оештыру комитеты утырышы беркетмәсе белән расланган

конкурс башлану турында оештыру комитеты карары кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Конкурслар» бүлегендә урнаштырыла.

## III. Конкурста катнашуга заявкалар бирү тәртибе

3.1. Конкурста катнашу өчен кандидатуралар кандидатның төп эш (уку) урыны буенча предприятиеләр, югары белем бирү оешмалары җитәкчеләре тарафыннан тәкъдим ителә.

3.2. Конкурста катнашу турындагы заявкага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

а) алдагы календарь елга инженерлык эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, конкурсның кандидат тәкъдим ителә торган категорияләрен һәм номинацияләрен күрсәтеп, карар-тәкъдимнамәләр; анда кандидат эшли, укый торган предприятиенең, югары белем бирү оешмасының һәм предприятиенең, югары белем бирү оешмасының структур бүлекчәсенең тулы исеме, шулай ук вазыйфаның тулы исеме (предприятие хезмәткәре өчен), әзерлек/белгечлек юнәлешенең тулы исеме (белем алучылар өчен). Карар-тәкъдимнамәләр предприятиенең, югары белем бирү оешмасының таләпләре нигезендә рәсми бланкта рәсмиләштерелә, аңа предприятие, югары белем бирү оешмасы җитәкчесенең яки имза куярга хокуклы һәм кандидатның конкурска тапшыра торган документларының эчтәлеге белән танышкан башка вазыйфаи зат тарафыннан кул куела.

б) югары белем бирү оешмасында белем алу турында белешмә кәгазе яки законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (предприятиеләр, югары белем бирү оешмалары хезмәткәрләре өчен);

в) Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклый торган төп документның күчермәсе;

г) югары белем турындагы дипломның күчермәсе, шулай ук гыйльми дәрәҗә булуны раслый торган дипломның күчермәсе (әгәр булса) (аспирантлар, предприятиеләр, югары белем бирү оешмалары хезмәткәрләре өчен);

д) оештыру комитеты тарафыннан формасы раслана торган һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

е) әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән конкурсантларның казанышларын бәяләү критерийларына карап, узган календарь ел йомгаклары буенча инженер эшчәнлеге өлкәсендә кандидатның казанышларын тасвирламасы; аңа уйлап табуга, файдалы модельгә яки сәнәгать үрнәгенә патентлар, электрон исәпләү машиналары өчен программаларны дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар, рецензияләнә торган басма һәм электрон фәнни һәм фәнни-техник басмаларда кандидат тарафыннан бастырып чыгарылган үткән календарь елга фәнни хезмәтләр исемлеген (булганда) теркәлә. Мәгълүмат кандидатның кулы куелган белешмә кәгазе рәвешендә (форматы А4 , шрифты 14 үлчәмдәге Times New Roman, интервалы берле) бирелә.

3.3. Конкурста катнашуга заявка конкурсның рәсми сайтында (документларның сканлаштырылган күчермәләре) тапшырыла яисә Министрлыкның 420111, Татарстан

Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан эш башкару һәм контроль бүлегенә кәгазь рәвешендә җибәрелә.

## IV. Конкурс комиссиясе һәм аның эш тәртибе

4.1. Конкурста катнашучыларның казанышларын бәяләү конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның составы оештыру комитеты тарафыннан раслана. Комиссия составына әйдәп баручы галимнәр, инженерлар, икътисадның төрле тармакларына караган белгечләр керә.

4.2. Комиссия комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

4.3. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм аның утырышларын үткәрә.

4.4. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, аның вәкаләтләре комиссия рәисе урынбасарына күчә.

4.5. Комиссия әгъзалары аның утырышларында алмаштыру хокукыннан башка катнаша.

4.6. Эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

4.7. Утырышта эшче төркем әгъзасы булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бирергә хокуклы.

4.8. Конкурс комиссиясе конкурста катнашуга заявканы түбәндәге очракларда кабул итми:

конкурсант әлеге Нигезләмәнең 1.5, 1.7 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгәндә;

конкурста катнашуга заявка әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктына туры килмәгәндә.

4.9. Комиссия конкурста катнашучыларның казанышларын әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты нигезендә 10 баллы шкала буенча конкурсның беренче (читтән торып үткәрелә торган) туры барышында да, икенче (турыдан-туры үткәрелә торган) туры кысаларында да бәяли.

4.10. Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.11. Комиссия утырышларында кабул ителә торган карарлар беркетмәләр рәвешендә рәсмиләштерелә, аларга утырышта рәислек итүченең кулы куела.

4.12. Комиссия әгъзасы конкурста катнашуга гариза биргән очракта, ул комиссия составыннан чыгарыла.

## V. Конкурста катнашучыларның казанышларын бәяләү критерийлары

5.1. Конкурста катнашучыларның казанышларын бәяләү комиссия тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча 10 баллы шкала буенча уздырыла:

проект темасының актуальлеге, аның Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе фәнни-технологик үсешенең стратегик приоритетларына туры килүе;

алынган нәтиҗәләрнең практик әһәмияте, аларның техник-икътисадый нәтиҗәсе;

техник фикерләүнең мөстәкыйльлеге, яңа материаллар, машиналар, приборлар, технологияләр эшләүдә, аларны үзләштерүдә катнашу дәрәҗәсе; патентлы үрнәк яисә технология булу;

проектлауның заманча ысулларына, шул исәптән модельләштерү нигезендә цифрлы алымнарына ия булу;

фәнни-техник мәгълүматны эзләү, анализлау һәм аны һөнәри эшчәнлектә куллану осталыгы;

проект эшендә экологик, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, сыйфат менеджменты системасына, «сак җитештерү» принципларына туры килгән булу;

техник мәсьәләләр буенча үз фикереңне белдерә, фән һәм техниканың заманча казанышлары турында белемнәрне күрсәтә белү;

өзлексез һөнәри белем бирүнең төрле рәвешләрендә катнашу.

## VI. Конкурсны уздыру һәм конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе

6.1. Конкурс һәр өч категориянең һәркайсында 12 номинация буенча ике турда уздырыла.

6.2. Беренче (читтән торып үткәрелә торган) тур барышында комиссия тарафыннан конкурста катнашуга заявкага кертелгән документлар нигезендә конкурста катнашучыларның казанышлары бәяләнә.

6.3. Конкурста казанышларны бәяләү әлеге Нигезләмәнең 4.9 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.4. Беренче (читтән торып үткәрелә торган) тур йомгаклары буенча комиссия һәр өч категориядә 12 номинациянең һәрберсе буенча иң күп баллар җыйган һәм икенче (турыдан-туры үткәрелә торган) турга рөхсәт ителгән иң күбе биш конкурста катнашучыны билгели.

6.5. Семинар рәвешендә икенче (турыдан-туры үткәрелә торган) турда катнашырга чакырылган конкурста катнашучылар үткән календарь ел йомгаклары буенча инженерлык эшчәнлеге өлкәсендә үз казанышларын тәкъдим итә.

6.6. Конкурста җиңүчеләр комиссия тарафыннан һәр 12 номинациянең һәркайсы буенча икенче (турыдан-туры үткәрелә торган) тур йомгаклары буенча иң күп баллар суммасы буенча билгеләнә.

6.7. Конкурста җиңүчеләр Татарстан Республикасы җитәкчелеге катнашында тантаналы чара кысаларында бүләкләнә.

6.8. Конкурс йомгаклары, комиссия тарафыннан конкурста җиңүчеләр билгеләгәннән соң 15 көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Конкурслар» бүлегендә урнаштырыла.